

# МӨХЛИСӘ БУБЫЙ ТУУЫНА – 150 ЕЛ

1869 елның 21 февралендә (хәзерге стиль белән 5 мартта) дөньяга килгән кыз бала – атаклы мәгърифәтче Бубыйлар нәселенең мәшһүр бер әгъзасы Мөхлисә Габделгалләм кызы Бобинская-Бубый. Ул егерме ел буена (1917-1937) Русия мөселманнарының диния идарәсе әгъзасы, ислам тарихында бүгенге көнгә кадәр бердәнбер булып калган казыя, ягъни шәригать кануннарын яхшы белүче хөкемдар булган.

Русиянең караңгы почмагы саналган Вятка губернасындагы Сарапул өязе, Иж-Бубый авылының (хәзер Татарстанның Әгерҗе районында) мәртәбәле имамы мөдәррис Нигъмәтулла улы Габделгалләм-хәзрәт (1834-1903) гаиләсендә туып үскән татар кызы ничек бу дәрәҗәгә лаек булган соң? Кайда белем алган, карашлары кайда һәм ничек формалашкан? Мөхлисә Бубыйның исемен һәм, бигрәк тә, аның күп еллар казыя хезмәтен башкаруы хакында ишеткән һәркемдә мондый сораулар туачагында шигем юк. Мәгълүм ки: мондый дәрәҗәгә укымышлы, ислам тәгълиматын тирән белгән, зур ихтирамга лаеклы шәхес кенә ирешә ала. Һәм бу чыннан да шулай булган.

Мөхлисә үскән чорда, ир балалар өчен мәктәп-мәдрәсәләр булса да, кызлар өчен махсус мәктәпләр булмаган. Аларга белем-тәрбияне абыстайлар (мулла хатыннары) биргән. Мөхлисә дә башлангыч белемне, башка авыл кызлары белән бергә, әнисеннән алган. Әнисе – Уфа губернасының Минзәлә өязе Чебенле (Тугыҗа) авылы имамы һәм мөдәррисе Иманкол Мәхмүд улының кызы Бәдрелбанат (1838-1922) - үз чоры өчен бик яхшы белемле булган. Абыстай, төпчек улы Габдулла язуынча, Габделгалләм хәзрәткә кияүгә чыкканда ук “галимә вә гарәпчә белән фарсычадан да яхшы ук хәбәрдар” булган, кияүгә чыккач та белем эстәвен дәвам иткән, Габделгалләм хәзрәттән балаларны укыту серләренә өйрәнгән. Үз өенә авыл кызларын җыеп, абыстай аларны укыткан, авыл хатын-кызларына дини-әхлакый тәрбия бирү юлында да зур тырышлык күрсәткән. Табигый ки, гел әнисе кул астында булган Мөхлисә бик кечкенә, өч-дүрт яшьлек чагында ук хәреф таный башлаган, укырга гына түгел, язарга да өйрәнгән (кызларга белем бирү

- аларны  укырга өйрәтү белән чикләнгән чор булуын онытмыйк). Кызы бераз үсә төшкәч, абыстай аны һәм тагын берничә сәләтле кызны гарәп-фарсы телләре белән дә таныштыра башлаган.

Сабый чактан ук кыз бала китап укырга яраткан. Шәкерт вакытында ук үз китапханәсен булдырырга тырышкан Габделгалләм хәзрәт, җае чыккан саен, аны дини тәгълиматка караган китаплар белән дә, шәрекъ-татар классик әсәрләре белән дә тулыландырып торган. Әлбәттә, кечкенә Мөхлисә “Кыйссаи Йосыф”, “Кисекбаш”, “Мөхәммәдия”, “Бәдәвам” кебек төрки классик әсәрләрне бирелеп укыган, “Сак-Сок” кебек бәет-мөнәҗәтләрне яттан белгән. Гарәп-фарсы телләре белән таныша башлагач, аның күңелен шәрекъ классикасы биләп алган. Яшүсмер чагыннан ук укуга һәвәс Мөхлисә этисе мәдрәсәдә укыта торган фәннәр белән дә кызыксынган. Абыйсы Гобәйдулла һәм энесе Габдулла укый торган китапларда аңа күп нәрсә аңлашылмаса да, җаен китереп, ул аларны да укырга тырышкан, аңламаганын исә кызыксынучан кыз эти-әнисеннән, абый-энесеннән сорашкан. Мөхлисәнең бетмәс-төкәнмәс сорауларына җавап бирә-бирә, этиәнисе һәм туганнары аңа ирләр мәдрәсәсе күләмендә төпле белем бирүгә ирешкәннәр.

1887 елның 12 февралендә 18 яшен дә тутырырга өлгермәгән Мөхлисәне Минзәлә өязе Мәчти авылының указлы мулласы 33 яшьлек Җәлалетдин Әхмәтҗан углына кияүгә биргәннәр. Инде берничә ел әнисенә кызлар укытуда ярдәм итеп килгән, үз эти-әнисе кебек, ире белән бергә авыл халкын агарту, мәгърифәтле итү турында хыялланган Мөхлисә. Ләкин бу өметләр, хыяллар бик тиз чәлперәмә килгән. Дуамал, бозык фигыльле, каты күңелле, укыту эшен бер дә яратмаган хәзрәт яшь абыстайның кызлар укыту теләгенә катгый каршы килгән. Иреннән күрмәгән хөрмәт-яратуны хатын-кыз, гадәттә, балаларында таба. Мөхлисә-абыстай монда да зур кайгы-хәсрәтләргә дучар булган.  Озак көтеп алган куанычы, матур гына үсә башлаган кызы Миңнебибинаҗия (02.12.1891-01.03.1893), яшь ярымын да тутырмыйча, вафат була. Асравы, якын сердәше бала тапканда фани дөньядан китеп бара. Абыстай аның ятим калган кызчыгын, Бибинаҗия исемен биреп, иренең ризалыгы булмаса да, тәрбиягә ала. Мөхлисә абыстай тагын ике кыз бала таба – Миңнемөнҗия (14.01.1895-1919) белән Миңнебибинаиләне (04.10.1897-29.11.1898). Кечкенә балалар үлеме бик күп булган бу чорда. Төпчеген югалткан абыстай үзенең исән калган кызларын – яшьтәшләр Наҗия (1894-1967) һәм Мөнҗияне (1895-1919) – күз карасы кебек сакларга тырышкан. Аның көннән-көн караңгылана, аяусызлана барган тормышында шушы ике сабый гына юанычы булган.

Ихтимал, Мөхлисә абыстайның язмышы да, башка күп кенә авыл муллаларының хатыннары язмышы кебек барган булыр иде, ләкин кыз туганнарына аларга Минзәлә ярминкәсеннән кайтышлый хәл белергә кергән абыйсы һәм энесе ярдәм иткән. Алар зур кайгыга баткан сеңелләрен һәм аның ике кызын, эти-әниләре янында бераз юаныч тапсын дип, үзләре белән Иж-Бубыйга алып киткәннәр.

Мөхлисәнең туган авылында зур үзгәрешләр башланган заман була бу.

Агалы-энеле Гобәйдулла һәм Габдулла мәхдүмнәрнең әти-әнисенең фатихасын алып, зур эшкә керешкән вакытка туры килгән бу вакыйга. Алар 1895 елда милләт киләчәге булган яшьләрне тәрбияләр өчен авылларында яңа белем-мәгърифәт учагы булдыру эшен башлап җибәргән булалар. Ирләр мәдрәсәсен үзгәртүдәге уңышлары аларда кыз балаларга да нигезле белем бирү өчен яңа типтагы кызлар мәктәбе төзү фикерен уяткан. Әлегә бертуган Бубыйлар күңелендә генә туып килгән яңа төр (җәдиди) кызлар мәктәбен аннан-моннан белем алган остабикә-абыстайлар кулына биреп булмый ич! Димәк, беренче чиратта, мәктәптә укыту өчен белемле мөгаллимәләр хәзерләргә кирәк. Һәм Бубыйлар үзләренең хәләл җефетләрен яңача укытырга-өйрәтергә керешкәннәр. Яшь абыстайлар исә, җиң сызганып, яңа эшкә өйрәнә һәм кызларны җәдид ысулы белән укыту-тәрбия эшен башлап та җибәргәннәр.

Моңа кадәр ишетеп кенә белгән бу үзгәрешләр Мөхлисә абыстайны үз эченә тартып ала. Яшьтән үк хатын-кызларны агарту, мәгърифәтле итү турында хыялланган Мөхлисә иреннән аерылырга, үзенең бөтен тормышын бу эшкә багышларга теләвен туганнарына җиткерә. Бубыйлар гаиләсе Мөхлисәнең карарын кабул итә. Күрәсең, үз гаепләрен яхшы аңлаган, Бубыйларның бу тәвәккәл адымына исе киткән Җәлалетдин хәзрәт, ачуы килсә дә, хатынын эзәрлекләмәгән, ләкин аермаган да. Бу вакыйгадан соң шактый вакыт үткәч кенә, казый Ризаэддин Фәхреддин биргән фәтва нигезендә, 1917 елда бу аерылышу рәсми төс алган.

Шушы вакыттан алып, Мөхлисә абыстай бертуганнарының хатыннары Нәсимә һәм Хөснифатыйма белән берлектә яңа төр кызлар мәдрәсәсен – дарелмөгаллимәт (мөгаллимәләр хәзерләү уку йорты – укытучылар институты) оештыру эшенә җаны-тәне белән бирелгән. 1901 елга ул моңа кадәр татар дөньясында булмаган кызлар өчен яңа алты сыйныфлы уку йорты булып өлгерә, һәм Мөхлисә абыстай аның мөдире итеп билгеләнә. Анда дин гыйлеме белән беррәттән төрле дөньяви фәннәр, ә 1905 елдан рус теле укытыла. 1907 елда Сарапул өязе земствосы акчасына 1 сыйныфлы рус-татар училищесе ачыла, ул дарелмөгаллимәтнең бер бүлегенә әверелә.

Бу елларда Мөхлисә абыстай ир туганнары ярдәме белән ирләр мәдрәсәсе программасының нигезен тәшкил иткән дини тәгълиматны өйрәнүне дә дәвам иткән. 1905 елга, ягъни Бубый мәдрәсәләре киң колач белән эшли башлаган вакытка, ул ислам динен яхшы белгән галимә булып җитешкән инде. Аны “мулла-абыстай” дип атый башлаганнар. Бу исем үзе үк Мөхлисә ханымның абруе бик югары булуын күрсәтүче, аның мәдрәсә җитәкчесе һәм югары белемле дин белгече булуын раслаучы фактор булып торган.

1907 елда Сарапул өяз земствосы бертуган Бубыйларның татар мәктәпләре өчен укытучылар хәзерләү эшен башкаруларын рәсми рәвештә таныган: аларга “татар мәктәпләрендә укытучы-мөгаллим” һәм “укытучы-мөгаллимә” исеменә имтихан алу һәм таныклык бирү хокукы бирелгән. Моңа кадәр мондый исемне рәсми рәвештә ирләргә бары тик Оренбург дини идарәсе генә бирүен искә алыйк. Укытучы хатын-кызларга исә бу вакытка

кадәр рәсми таныклык бирүче уку йорты булмаган. Габдулла Бубый сүзләре белән әйтсәк, “Русиядә иң элек ислах кылынган вә иң элек мөгаллимәләр чыгара башлаган кызлар мәктәбе менә шушы Бубый кызлар мәктәбе” була. Беренчеләрдән булып, “укытучы-мөгаллимә” таныклыгы Мөхлисә ханымга һәм кызлар мәдрәсәсенең башка мөгаллимәләренә тапшырылган. Таныклыклар, рәсми документ буларак, барлык административ оешмалар тарафыннан кабул ителергә тиеш булуын да ассызыклыйк. Шуны да кисәтергә кирәк: земствоның бу карары бик вакытлы кабул ителгән булып чыга, чөнки патша хөкүмәте татар милли-мәдәни хәрәкәтенә каршы чаралар хәзерләгән дәвергә туры килгән бу адым.

Дарелмөгаллимәттә дин нигезләре, дөньяви фәннәр, ягъни төрки-татар, гарәп, фарсы, рус телләре, география, гомуми тарих, риторика, математика, физика, зоология, ботаника, моннан тыш хатын-кыз өчен әхлак (һәм психология), гигиена, балалар тәрбиясе, йорт (хуҗалык) алып бару, кул эшләре кебек мөһим дәресләр дә булган. 1908 нче елдан башлап, Иж-Бубыйда мөгаллим һәм мөгаллимәләр өчен өч айлык җәйге курслар эшләп килә. Бу курсларны тәмамлаучыларга да хөкүмәт тарафыннан рөхсәт ителгән мөгаллимлек һәм мөгаллимәлек таныклыклары тапшырыла. Иж-Бубый мәдрәсәсендә Россиянең төрле почмакларыннан, бигрәк тә  Казан, Себер, Зайсан (Казахстан), Ташкент, Пржевальск, Бишкек, Уфа, Бөгелмә, Касыйм, Төмән, Әстерхан һәм башка ерак җирләрдән килеп укучы хатын-кызлар күп булган. Кызларның бер өлеше  тулай торакта яшәгән, урын җитмәгәннәр авыл кешеләрендә фатирда торганнар. 1905-1912 елларда Иж-Бубыйда кызлар гына түгел, төрле яшьтәге хатыннар да белем алган.  Аналары белән бер үк вакытта кызлары да укырга килгән. Имчәк балалары белән килгән хатыннарны да укырга кабул иткәннәр бу мәктәптә.

1905-1907 еллар революциясеннән соң хакимият революция елларында киң җәелеш тапкан, ләкин рәсми оешмаларның рөхсәтеннән башка гына ачылган җәдид мәктәпләрен ябу эшенә тотынган (мондый мәктәпләрне оештырып җибәргән мөгаллим-мөгаллимәләрнең үзләренең дә күп очракта яраклы документлары булмавы хакында да әйтү мөһим). Бу эшне патша хакимияте Иж-Бубый белем учагын җимерүдән башлаган: 1911 елның 30 гыйнварына каршы төндә Иж-Бубыйга йөзләгән атлы стражникны ияртеп жандарм ротмистры Будогоский килә. Бубый мәгариф учагын тар-мар итү өч көнгә сузыла. Ирләр мәктәп-мәдрәсәләре ябыла, барлык мөгаллимнәр һәм Гобәйдулла белән Габдулла Бубыйлар кулга алына, Сарапул төрмәсенә җибәрелә.

Шулай уңышлы эшләп килгән Бубыйлар гаиләсе тормышында фаҗигале чор башланган. Иректә калган хатын-кызлар билгесезлек шартларында төшенкелеккә бирелмәгәннәр, бар авырлыкны үз җилкәләренә алганнар. Үрнәкне әниләре Бәдрелбанат абыстай күрсәткән. Мөхлисә ханым һәм аның ярдәмчеләре кызлар мәдрәсәсен саклап калу өчен бар көчләрен, бар тырышлыкларын куйганнар. Җирле хакимият кызлар мәдрәсәсен Бубыйларның үзләреннән яптырыр өчен төрле куркыту чаралары кулланып караган булса да, уңышка ирешә алмаган. Мөхлисә ханым җитәкләгән мөгаллимәләр мәдрәсәдә кызларны укытуны туктатмаган. Ниһаять, 1912 елның 18 гыйнварында Бубый кызлар мәктәбе дә Вятка губернасының халык

мәктәпләре директоры карары белән ябылган.

1912 елда Мөхлисә абыстай Троицк шәһәренә күчеп китә һәм анда 1910 елда ачылган башлангыч хатын-кызлар мәктәбен Бубый тәҗрибәсе нигезендә үзгәртергә керешә. Бер үк вакытта 1913 елдан ул кызлар гимназиясендә дин гыйлеме укыта. 1914 елда ул сәүдәгәр Яушевларның матди ярдәме белән хатын-кызлар мәдрәсәсе, 1915 елда мөгаллимәләр семинариясен ачуга ирешә.

Мөхлисә Бубыйның тормышы 1917 елда тагын бер тапкыр кискен үзгәреш ала. Бу үзгәреш, әлбәттә, илдә башланган үзгәрешләр белән тыгыз бәйләнештә була. Бөтенроссия мөселманнарының беренче корылтаенда (Мәскәү, 1-10 май, 1917) ул Мөселманнар Диния нәзарәте әгъзасы һәм казыя итеп сайлана. Бу хәлне анализлап, "Сөембикә" журналының нашире һәм мөхәррире Якуб Хәлили түбәндәге сүзләрне язган: "Идарәи диниягә биш казыйның берсе хатыннардан сайланды. Без ислам галәмендә мөслимә казыяның барлыгын белмибез. Ислам мәмләкәте булган Төркиядә дә хатыннардан казыя барлыгын ишеткәнебез юк. Менә бу, мөслимә казыя сайланып куелу, хатыннар съезды, хатыннар тавышының тәэсире белән булган эштер. Менә бу гамәлдә үк хиҗапның беткәнлеген, ир белән хатынның эштә, хокукта тигезлеген күрсәткән бер факттыр".

Мөхлисә Бубый, 1917 елның җәендә гомеренең Троицк чорын тәмамлап, Уфага күченә. Мөхлисә ханым шөһрәтле дин белгечләре мөфтиләр Галимҗан Баруди (1857 -1921) һәм Ризаэддин Фәхреддин (1859-1936) җитәкчелегендә хатын-кызлар арасында зур оештыру, аңлату эшләре алып бара. Ул 20 ел дәвамында (1917-1937) Диния нәзарәтенең гаилә эшләре бүлеге белән җитәкчелек итә, метрика кенәгәләрен тутыру, гаилә мөнәсәбәтләрен җайга салу, ислам диненә дәгъватлау һ.б. эшләр белән шөгыльләнә. 1924–1927 елларда Дини идарәнең "Ислам мәҗәлләсе" исемле журналында Мөхлисә ханым мәкаләләр белән дә катнашкан, төрле дини мәсьәләләргә кагылышлы фәтвалар да язган, бәхәсле гаилә мәсьәләләрен хәл иткәндә хөкемдар да булган.

Аның моннан туксан биш ел элек басылган мәкаләләрендәге фикерләре бүген дә үзенең актуальлеген югалтмаган. Мисал өчен журналның беренче санында ук басылган "Ислам дөньясында хатыннар" исемле мәкаләне китерү дә җитә. Бу мәкаләдә М.Бубый, Мөхәммәт пәйгамбәр заманыннан башлап, хатын-кызларның гаилә һәм җәмгыятьтәге ролен бәяләгән һәм алар алдында үз чоры куйган таләпләргә тукталган. "Хезмәтләрнең зурлыгы вә азлыгы, файдалы булуы ихтыяҗга карап йөри. Дөньяда шундый урыннар вә шундый вакытлар була – башка бер урында вә башка бер заманда санга алынмый торган бер хезмәт бик файдалы вә бик кирәкле булып чыгадыр, - дип башланган мәкаләнең бу өлеше. – Безнең шушы өлкәбездә вә шушы көннәребездә хатыннарга йөкләнә торган авыр түгел, әмма үзләре бик кирәкле вә файдалы хезмәтләр бар. Шул хезмәтләрне итү алар өстенә төшкән бер бурыч. Әмма бурычны түләү чиксез рәвештә сәдакалар өләшүгә караганда да файдалы вә саваплы булуында шөбһә юк". Беренче бурыч – "үзебезнең дини гадәтләребезне вә бәйрәмнәребезне саклау", - дип күрсәткән Мөхлисә ханым.

Хатын-кызларга ул замандагы вәзгыять йөкләгән икенче бурычны ул

бик нигезле итеп дәлилләгән. Бу дәлилләр хәзерге заман хатын-кызлары күңеленә барып җитсә дә файдалы булыр иде. “Ул бурычлардан икенчесе – тел саклау. Бу көн безнең юлга салынган вә дөньяның йомышларын гына түгел, хәтта дин вә гыйлем тугрысындагы йомышларыбызны үтәрлек үз арабызда куллана торган телебез бар, - дип башлаган ул дәлилләвен. – Гәрчә арада читләрдән кергән сүзләр күп булса да, ул сүзләр инде үз малыбыз булып киткән, төркичә булып саналу тиешле күрелгән. Димәк, бик яхшы вә җитеш телебез бар. Сөйләшәсе килгән кеше аптырап торырлык түгел. Эш шулай була торып, шәһәр-авылларда кирәгеннән артык, хәтта бөтенләй кирәкми вә килешми торган урыннарда рус сүзе истигъмаль ителенә (*кулланыла*) башлаганлыгы күренәдер”.

Бу сүзләренә мисал китергәннән соң ул: “Халкыбыз русча белсен, кулыннан килсә, башка телләр берлә дә ашна (*таныш, хәбәрдар*) булсын, белү бик кирәк, әмма үз сүзебез арасына урынлы-урынсыз, кирәкле-кирәксез чит телләрне катнаштыру инде бер дә килешми, - дип дәвам иткән Мөхлисә ханым. - ... Дөньяда булган һәр төрле кавемнәрнең телләрен саклаучылар шул кавемнәрнең аналары вә хатыннары булган хәлдә, безнең халкыбызның телләрен саклаучылар да үзләренең аналары вә хатыннары булырга тиешле. Безнең халкыбызның аналары, хатыннары зирәклек вә һиммәт (*тырышлык, ялкынлы дәрт*) тугрысында башкалардан ким түгел”. Бу мәкаләдәге фикерләр, күргәнебезчә, бүген дә әһәмиятле булып кала.

XX гасырның 20-30 елларында татар зыялыларына кагылган эзәрлекләүләр Мөхлисә ханымны да, өлкән яшьтә булуына карамастан, читләтеп үтмәгән. НКВД органнары тикшерүчеләре алдына ул 1930 елның 21 сентябрендә беренче мәртәбә килеп баскан. Бу көнне аны, Җинаять кодексының 59-статьясы буенча, алтын акча һәм кыйммәтле әйберләрне законсыз саклауда гаепләп, сорау алуга тартканнар. Мөхлисә ханымның Мәккәгә хаҗ кылу ниятеннән җыеп килгән барлык “байлыгы” тартып алынган. Шулай да, бу юлы ул үзе иректә калган. Икенче юлы Мөхлисә ханым 1930 елдагы кебек “җиңел генә” котыла алмаган...

1937 елның 20 ноябрендә Мөхлисә Бобинская (Бубый) кулга алынган. Егерме елдан артык гомерен Русия мөслимәләре арасында мәгърифәт таратуга багышлаган сәләтле педагог, тагын шул кадәр үк гомерен Русия мөселманнарының үзәк дини идарәсендә эшкә биргән абруйлы казыя, Мөхлисә ханым Бубый 1937 елның 30 ноябрендә Башкортостан АССР НКВД-сы “өчлеге” утырышында “Башкортостанда контрреволюцион баш күтәрүче милләтчеләр оешмасы”нда катнашуда гаепләнгән һәм атарга хөкем ителгән. 68 яшьлек Мөхлисә–абыстай һәм тагын алты мөселман рухание 1937 елның 23 декабрендә атылганнар. Башкортостан АССР Югары суды президиумының 1960 ел 23 май карары белән аларның барысы да гаепсез дип табылган һәм акланган.

Менә бу искиткеч шәхес – Мөхлисә Габделгалләм кызы Бубый тормышының кайбер мизгелләре. Мөхлисә ханым, ир туганнары кебек үк, үзенең фидакарь хезмәтен, барлык тормышын халкына, аны агартуга багышлаган шәхес. Гомумән, чынбарлык Бубыйлар гаиләсенә, илгә нинди

генә сынаулар алып килсә дә, Мөхлисә ханым төшенкелеккә бирелмәгән, яшьлегендә сайлаган юлдан тайпылмаган, соңгы сулышына кадәр бөек максатына тугры булып калган. Бу фидакарьлекне ничек аңлатырга соң? Мөхлисә Бубый шәхесенең үзенчәлекләре беләнме? Яки моны татар җәдидчелегенең бер күренеше буларак кабул итәргәме? Революцияләр шартларында яңа җәмгыять, яңа дәүләт төзү хыялы белән яшәгән, җәдидчелек идеалларын тормышка ашырырга тырышкан барлык фидакарьләр дә аңа ошаганмы? Сораулар, сораулар... Ничек кенә булмасын, безгә Мөхлисә ханым кебек шәхесләрнең якты истәлеге алдында баш иярга, аларны сакларга гына кала.

Мәхмүтова А.Х.,
тарих фәннәре кандидаты,
Ш.Мәрҗани ис. бүләк лауреаты



Здание женского медресе 1908-1910 гг.



М.Буби и члены Духовного собрания с делегатами съезда Уфа, 1926



М.Буби среди учениц женского медресе Иж-Буби 1910



Семья Буби Сарапул, 1912